**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге Биккол авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«29» июль 2025 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге Биккол авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Гражданнар җыенына чыгарылган сорауга элек расланган сорауларга үзгәрешләр кертергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 12.11.2024 ел, № 1 карар
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 2024 елның 12 ноябрендәге 2 номерлы карары,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

«Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Биккол торак пункты чикләрендә җирле әһәмиятле юлларны кышкы карап тоту).»

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Х.Әхмәтшина

Биккол авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Әхмәтшина